## Туган якка тугрылык

Туган як... Шагыйрь өчен «туган як» төшенчәсе гаять киң колачлы. Әйтик, Таһир Шәмсуаров, Гәрәй Рәхим кебек авыл малайлары өчен туган як ул — Иске Иштирәк, Федотовка кебек гап-гади, әмма әлеге малайлар өчен дөньяның кыл уртасы, бөтен дөнья географиясенең йөзек кашы булган гүзәл бер табигать почмагы. Дөньяга, бигрәк тә шигърият дөньясына тирәнрәк керә барган саен, «туган як» төшенчәсенең колачы киңәя, мәгънәсе зурая башлый. Әйтик, Татарстан күзлегеннән караганда, безнең «туган як» ул — тарихилыгы, табигате, күңелгә якынлыгы белән дөньяда тиңдәшсез Шөгер дигән бер төбәк. Россия күзлегеннән караганда, «Туган як» ул — сөекле Ватаныбыз Татарстан. Ә инде халыкара күзлектән караганда, «туган як» — Җир шарының борынгы төркиләр, Болгар, Алтын Урда, Россия дәүләте, Идел һәм Урал буйларындагы төрки, фин-угор, урыс һәм башка милләтләр яши торган гаять зур географик кыйтга.

Таһир Шәмсуаров туган Иске Иштирәк авылының тарихы ерак гасырларга кереп югала. «Югала» диюемнең сәбәбе шул: бездә әле авыллар тарихы бик аз өйрәнелгән, оятыбызга каршы, без үзебезнең «туган як» тарихыбызны бик аз беләбез.

Исеме буенча Иске Иштирәк авылының борынгы тарихы нугайларга барып тоташа булса

кирәк. Нугай ханлыгында иң атаклы, иң көчле, кыю һәм зирәк ханнарның берсе Иштирәк хан булган. Аның биләмәләрендә төпләнеп калган байтак авыллар үзләренә бөек хан исемен алганнар. Мин белгәне генә дә Татарстан һәм Башкортстанда берничә Иштирәк авылы бар. Бу авыллар арасында Таһир Шәмсуаров туган Иске Иштирәк авылы исә географик яктан шактый аерылып тора. Билгеле булганча, нугайлар, нигездә, дала халкы. Аларның бөтен тарихи тормышы далада уза. Нугайлар үзләренә яңа җирләр үзләштергәндә куе урманнарга килеп терәлгәннәр дә, үз биләмәләренең чиген әнә шул «урман-дала» дип аталган географик сызыкта билгеләгәннәр. Иске Иштирәк авылы нәкъ әнә шул «урман-дала» дип аталган урман һәм дала кушылган чиктә урнашкан. Шулай итеп, Иске Иштирәк халкында дала халкының гореф-гадәтләре, рухи үзенчәлекләре белән урман кешеләренең тормыш-көнкүреш, яшәү рәвешләре үрелеп үскән. Ә бу исә халыкның көнкүреш һәм рухи тормышын баеткан, төрлеләндергән. Шагыйрь Таһир Шәмсуаров шигырьләрендәге иксез-чиксез дала киңлекләре, даладагы меңнәрчә төсләрдә балкыган чәчәкләр-үләннәр, ап-ачык күк гөмбәзе, шул ук вакытта кара урманнар серлелеге, Шушма елгасы тугайларындагы гүзәл әрәмәләр, чишмәләр сурәте әнә шуннан килә. Шуңа күрә Таһир иҗатындагы авыл кешеләре үзгә, болын, кырлар, урманнар үзгә, сөйләм теле, моң, фикерләү рәвеше үзгә... Үзе үзгә, үзе нәкъ безнеңчә — саф төрки-татарча!

Таһир Шәмсуаров туган Иске Иштирәк һәм нугай халкының бөек улы Иштирәк ханның исемнәре дә, минем шигъри тоемым буенча, га-

ять ипле, төркиләрнең холык-фигылен чагылдыра торган ике сүздән гыйбарәттер кебек — Иш (дус-иш мәгънәсендә) һәм Терәк (ягъни ышанычлы, яклаучы булу, терәк булу). Шушы шигъри фаразга нигезләнеп бүген шагыйрь Таһир Шәмсуаров, аяк терәп, «Иштирәгем, минем терәгем» дип әйтә алыр иде. Шагыйрь иҗатының буеннан-буена шушы фикерне киңәйтә бара, шигырьләрендә Иске Иштирәкне генә түгел, ә Шөгер төбәген дә, туган Татарстанын да, тарихи татар халкын да, үзе яшәгән заманны да, бөтен җиһанны рухи терәге итеп сурәтли:

Яшь чагында без мең төрле
Уйлар уйлаган идек.
Әтиләр салган өйләргә
Никтер сыймаган идек...
...Җиһанны иңли ала тик
Сабыйлык күзе генә;
Әйләнеп кайттым әтинең
Гап-гади нигезенә.

Таһир Шәмсуаров Иске Иштирәктә туып үссә дә, гомеренең шактый өлешен, ә шигъри, иҗади гомеренең төп өлешен дүрт чакрым гына ераклыктагы Мөэмин-Каратай авылында үткәрә, ул бүгенге көндә дә шунда яши.

Мөэмин-Каратай — тарихы һәм урнашкан урыны ягыннан Шөгер төбәгендәге иң кызыклы авыллардан берсе. Авылның көнбатыш ягына кара урман терәлеп тора, көньягыннан исә иксез-чиксез нугай далалары сузылып китә. Татарстанны бөтен илгә, дөньяга таныткан нефть беренче булып дүрт чакрым ераклыктагы Иске Шөгер авылы басуында табыла. Бөтен Русиягә һәм чит илләргә даны таралган «Бәкер» курорты Мөэмин-Каратай җирләреннән күренеп үк тора.

Көньяк-көнбатыш ягыннан, авылга терәлеп диярлек, тугай-болыннарга гаять бай булган гүзәл Шушма елгасы ага, ә көнчыгыш ягыннан атаклы Шандор тавы күтәрелә. Бу тауларның аргы ягында әле XIX гасырда ук Америка нефть эзләүчесе Шандор тауны тишеп шурфлар ясаган һәм битум чыгарган.

Мөэмин-Каратайның тирә-ягында аллы-гөлле чәчәкләр белән тулы болыннар җәйрәп ята, тау битләрендә ап-ак кылганнар җилферди, урманнарында күптөрле җәнлек-җанвар, кош-корт, чәчәкле аланнар, җиләк-гөмбәләр шыгрым тулы... Юк, табигатьнең мондый оҗмахка тиң урынында илһамланмыйча, шигырь язмыйча мөмкин түгел. Һәм Таһир Шәмсуаров «бөтен уңайлыклары да булган» шәһәрләргә ашыкмый. «Башкалада күренекле шагыйрь булырмын» дигән азгын һәм, нигездә, ялган ымсынуга бирешми, гаиләсе белән шушы авылда төпләнеп кала, төп шөгыле булган мөгаллимлек эшен дәвам итә.

Шагыйрь Таһир Шәмсуаровның бөтен шигъри сәләте, шигъри тәҗрибәсе, шигъри өлгергәнлеге шушы авыл белән бәйле. Дөрес, ул бу төбәктәге әдәби хәрәкәткә якыннан катнаша, күренекле язучыбыз Шамил Бикчурин төзегән әдәби түгәрәктә иҗади чыныгу ала. Беренче тапкыр без Таһир белән хәзер «Чишмә» дип атала торган шушы әдәби түгәрәктә таныштык һәм иҗади мөнәсәбәтләребез бүгенгә кадәр дәвам итә, Аллага шөкер. Әйтергә кирәк, Шөгер һәм Лениногорск төбәгенең әдәби тарихы бик бай. Инде VIII йөздә үк мондагы Тимәш авылында яшәп иҗат иткән күренекле татар шагыйре Габдерәхим Утыз Имәни шушы җирлектә татар язма шигъриятенең атасы Кол Галинең «Йосыф-Зөләйха» әсәре

кульъязмаларын фәнни гомумиләштереп, беренче мәртәбә китап итеп бастырып чыгара. Аның улы, шулай ук билгеле татар шагыйре Әхмәтҗан, элеккеге Шөгер районының Сарабиккол авылында яшәп, «Йосыф-Зөләйха» кыйссасын нәшрият өчен күчереп яза. Бу төбәктә Таһир белән безнең каләмдәшләребез, татар әдәбиятында билгеле эз калдырган язучылар яшәп иҗат итте — Шамил Бикчурин, Җәмит Рәхимов, Рамазан Байтимеров, Роза Хафизова, Әсрар Галиев, Мәхмүт Газизов, Разим Вәлиуллин... Таһирның якташ-каләмдәшләре, Татарстанның күренекле язучылары Альберт Хәсәнов, Җәүдәт Дәрзаман, Рәмзия Габделхакова һәм «Чишмә» әдәби берләшмәсендәге күп кенә яшь һәм башлап язучылар яңадан-яңа әсәрләр иҗат итәләр. Әлбәттә, мондый әдәби мохит Таһир Шәмсуаровка яңадан-яңа иҗади илһам өсти.

Таһир Шәмсуаров, нигездә, лирик шагыйрь дип исәпләнсә дә, шагыйрь иҗаты иҗтимагый, шигъри публицистикага да бай. Ул кичәге һәм бүгенге авыл кешесенең яшәү рәвешен, уй-хисләрен, эчке кичерешләрен озак еллар буе шәһәрдә яшәп иҗат иткән шагыйрьләребезгә караганда яхшырак белә һәм авыл, табигать, туган як турындагы шигырьләрне безгә караганда үзгәрәк һәм күбрәк яза, бүгенге поэзиябезне әнә шул яктан сизелерлек баета.

Аның каләменнән борынгы, чын авыл кешесе хисләре түгелә:

Чалкан ятып көзнең мендәренә,
Мәтрүшкәләр моңын тоямын.
Куе сөттәй кәгазь битләренә
Мәрҗәнгә тиң сүзләр уямын.